БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«__24__» ___01____ 20 20 ел № _40___

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү турында**

2004 елның 29 декаберендәге 190-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 16 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләргә.

2. Расларга:

2.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча эшләр башкару тәртибе һәм вакытлары (1 нче кушымта).

2.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча кызыксынган затларның тәкъдимнәрен комиссиягә җибәрү тәртибе (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының http:/baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның ________________
______ номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча эшләр башкару тәртибе һәм вакытлары

| т/б № | Чаралар исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү |
| 2. | Комиссия тарафыннан җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын район башкарма комитетына тикшерү өчен җибәрү |
| 3. | Район башкарма комитеты тарафыннан җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын тикшерү һәм аны Норма авыл җирлеге башлыгына җибәрү; проект таләпләргә һәм документларга туры килмәгән очракта - аны комиссиягә эшләп бетерергә җибәрү |
| 4. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында карар кабул итү |
| 5. | Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында мәгълүматны бастырып чыгару |
| 6. | Кызыксынган затлар тарафыннан комиссиягә проект буенча тәкъдимнәр җибәрү |
| 7. | Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү процедурасын тәмамлау |
| 8. | Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан проектка үзгәрешләр кертү |
| 9. | Норма авыл җирлеге башлыгына гавами тыңлауларның беркетмәләре һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә белән проект җибәрү |
| 10. | Норма авыл җирлеге башлыгы тарафыннан Балтач муниципаль районы Советына раслау өчен проект җибәрү |

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның ___________________
________ номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча кызыксынган затларның тәкъдимнәрен комиссиягә җибәрү тәртибе

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча кызыксынган затларның тәкъдимнәре түбәндәге адресларга җибәрелә:

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына 422250, Татарстан Республикасы, Балтач районы, Балтач штп., Ленин урамы, 42 нче йорт, 118 нче кабинет адресы буенча.
- Норма авыл җирлеге башкарма комитетына 422243, Татарстан Республикасы, Балтач районы, Норма авылы, М.Җәлил урамы, 2а нчы йорт адресы буенча.

Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

- мөрәҗәгать җибәрүченең адресы;
- элемтә өчен телефоннар;
- юридик затның исеме; җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (юридик затлар өчен);
- юридик зат булып оешмаган физик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен фамилиясе, исеме, атасының исеме.

Мөрәҗәгатьтәге тәкъдимнәр логик рәвештә бәян ителгән һәм мотивацияләнгән булырга, текст А4 форматындагы кәгазьдә язылган, укырга уңайлы булырга тиеш.